**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2956**
**10.06.2019**

Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 8 июлендәге 4039 нчы карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3266 нчы, 2018 елның 20 июнендәге 3510 нчы, 2019 елның 8 маендагы 2397 нче карарлары редакциясендә) расланган күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>- күчемсез милек объектлары турында соралган мәгълүматлар булмау;<br>- соралган мәгълүматларда дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булу | |

2) 3.4.1 пунктның 2 пунктчасында:

- «белешмәләр» сүзен «хатлар» сүзенә алмаштырырга;

- «кире кагу турында хат» сүзләрен «кире кагу турында хат проекты» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3.4.2 пунктта «белешмәләр» сүзен «хатлар» сүзенә алмаштырырга;

4) 3.4.3 пунктта:

- «белешмәләр» сүзен «хатлар» сүзенә алмаштырырга;

- «белешмә» сүзен «хат» сүзенә алмаштырырга;

5) в пункте 3.5.1 пунктта «белешмәне», «белешмә» сүзләрен «хат» сүзенә алмаштырырга;

6) 3 нче кушымтада:

- «белешмәләр» сүзен «хатлар» сүзенә алмаштырырга;

- «белешмәне», «белешмә» сүзләрен «хат» сүзенә алмаштырырга;

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карар имзаланган көннән башлап җиде көн срокта аны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин